СОВЕТ ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с..Верхняя Ошма, д.54 а, с. Верхняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., №54а нче йорт,ЮгарыУшма авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение                                                    Карар
24 сентябрь 2018 ел                                        № 1-36

Югары Ушма авыл җирлеге Советының
2016 елның 3 октябрендәге
«Җир салымы турында» 2-13 номерлы
карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр
кертү турында

2018 елның 30 августындагы 02-01-18-2018 номерлы прокурор тәкъдиме, 2018 елның 03августындагы № 334-ФЗ Федераль закон, РФ Салым кодексының 391 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1 Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге «Җир салымы турында» 2-13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- карарның 3 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвалидлыкның I һәм II төркеме булган инвалидлар, балачактан инвалидлар, инвалид балалар, торак фонды, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән җирләргә, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек өчен бирелгән җирләргә, шулай ук дача хуҗалыгына, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга яисә гомерлек мирас итеп биләүгә бирелгән җирләргә карата».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә «Нократ» («Вятка») район газетасында, Мамадыш муниципаль районының (http://mamadysh.tatarstan.ru) рәсми сайтында, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы И.З.Исмагиловка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.З.Исмагилов